**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ НОВОАЛИМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт.

РЕШЕНИЕ КАРАР

08.04.2021 г. № 7

**«Яңа Әлем авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибен раслау турында» 2007 елның 05 октябрендәге 7 номерлы Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив-хокукый актларны «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. « Яңа Әлем авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибен раслау турында» 2007 елның 05 октябрендәге 7 номерлы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 9 пунктындагы 3 пунктчасында «Хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Яңа Әлем җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Яңа Әлем авыл җирлеге Советы Башлыгы Д.М.Әнварова